Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлегенең Аюкөйдергән авылында гражданнар җыенының 2020 елның 10нчы ноябрендәге 3 номерлы "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Аюкөйдергән авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм 2021 елда үзара салым кертү турында" карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чирмешән авыл җирлегенең Аюкөйдергән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш),500 (биш йөз) сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертүгә рөхсәт итәсезме?»дигән мәсьәлә буенча 2020 елның 10 ноябрендә Чирмешән авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:

- Аюкөдергән авылындагы Нариман урамы буенча вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту юлы белән автомобиль юлларын ремонтлау;
- МТЗ-82 тракторына чапкыч һәм бульдозер сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 113 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 73 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 73 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Чирмешән авыл җирлегенең Аюкөйдергән авылында халык җыенын узган дип , халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.« Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Аюкөйдергән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлар , балачактан инвалидлар; коляскадагы инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдән тыш),2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме дигән мәсьәлә буенча

карар кабул ителгән дип таныргa һәм - түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

- МТЗ-82 тракторына чапкыч һәм бульдозер   сатып алу.

- Аюкөдергән авылындагы Нариман урамы буенча җирле әһәмияттәге юлларны вак таш җәю һәм карап тоту юлы белән автомобиль юлларын ремонтлау.

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Аюкөйдергән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә (көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, балачактан инвалидлар; коляскалы инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдән тыш) 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- МТЗ-82 тракторына чапкыч һәм бульдозер   сатып алу.

- Аюкөдергән авылындагы Нариман урамы буенча вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту юлы белән автомобиль юлларын ремонтлау.

4.Гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

**Чирмешән авыл җирлеге башлыгы** **А. Т. Зиннәтуллин**